**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 23 «08» июль 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр тибындагы Актүбә бистәсе Советының 14.12.2017 № 36 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативлары турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында (13.12.2018 № 65, 24.05.2019 № 22, 20.08.2019 № 36, 16.12.2019 № 53, 24.04.2020 № 16 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын үтәү йөзеннән, 05.04.2021 №79-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 27.07.2020 № 1122 карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 19.09.2019 № 557/пр боерыгы нигезендә,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр тибындагы Актүбә бистәсе Советының 14.12.2017 № 36 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативлары турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларына (13.12.2018 № 65, 24.05.2019 № 22, 20.08.2019 № 36, 16.12.2019 №53, 24.04.2020 № 16 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.2 бүлегендәге 4.2.37 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Усадьба төзелеше районнарында араны кабул итәргә кирәк (СП 42.13330.2016):
Күрше җир кишәрлекләрендә урнашкан йорт һәм хуҗалык корылмалары (сарай, гараж, мунча) диварларына кадәр торак биналар тәрәзәләреннән 6 метрдан да ким булмаска тиеш. Үзәкләштерелгән канализация булмаганда, бәдрәфтән якындагы йорт диварларына кадәр араны 12 метрдан да ким булмаган, су белән тәэмин итү чыганагына кадәр (кое) - 25 метрдан да ким булмаган араны кабул итәргә кирәк.».

1.2. 4.8 разделында:

а) 4.8.18 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үләт базлары (биотермик чокырлар) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 26.10.2020 № 626 боерыгы белән расланган биологик калдыкларны күчерү, саклау, эшкәртү һәм утильләштерү ветеринария кагыйдәләре таләпләре нигезендә проектлана.»;

б) 4.8.21 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Санитар-саклау зонасы күләме:

- чокырларда күмелгән үләт базыннан - 1000 м.;
- биологик камералы үләт базыннан - 500 м.».

1.3. 6.1 бүлегендәге 6.1.7 пунктында «шәхси гараж» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен гаражлар төзү» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. «Ветеринария-санитария кагыйдәләре» бүлегендә 1 нче кушымтада:

а) «Ветеринария-санитария кагыйдәләре» сүзләрен «Ветеринария кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 26.10.2020 № 626 боерыгы белән расланган биологик калдыкларны күчерү, саклау, эшкәртү һәм утильләштерү буенча ветеринария кагыйдәләре.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru. һәм «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис А.Л. Севостьянов